**Класс:** 6

**Укытучы:** Шакирова Рузилә Рәисовна

**Программа:** Агибалова Е.В.  Гомуми тарих. Урта гасырлар тарихы. 6 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / - Казан: Татар.кит. нәшр., 2020.

**Тема:** Бөек Карл империясе төзелү һәм таркалу

**Максаты**: Бөек Карл империясе төзелү һәм таркалу сәбәпләрен ачыклау; укучыларда тарих фәненә кызыксыну тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗә:** карта белән эш,  яңа терминнарны үзләштерү.

I **лекция**

**Исәнмесез, укучылар! Европадагы һәрбер ил Урта гасырлар дөньясы формалашуга үз өлешен кертә. Без игътибарыбызны Көнбатыш Европаның кайбер иң зур халыкларына һәм бу чорның аңа хас үзенчәлекләре аеруча нык чагылган дәүләтләренә юнәлтербез.**

**Тема: “Бөек Карл империясе төзелү һәм таркалу” . Теманы өйрәнгәндә түбәндәге бүлекләргә тукталырбыз: (2 слайд)**

46 ел дәвамында (768 елдан 814 елга кадәр) Франк корольлеге белән Карсак Пипинның улы, Бөек дип йөртелгән Карл идарә итә.

**(3 слайд)** Карл озын буйлы, гаҗәеп көчле һәм бик чыдам кеше була. Ул 70 яшендә вафат була, ягъни шул вакытлар өчен гаять озын гомер кичерә. Замандашлары аның озак яшәвен Алла тарафыннан сайлап алынуына юрыйлар. Урта гасырларда Бөек Карл турында бик күп легендалар һәм җырлар иҗат ителә. Язучылар һәм хроникачылар аның сугышчан җиңүләренә, гаделлегенә һәм зирәклегенә дан җырлыйлар. Аның исеменең латинча яңгырашында (Каролус) Европа идарәчеләре үзләрен корольләр дип йөртә башлый.

**(4 слайд)** Һәр елны диярлек Карл зур гаскәр башында ерак җирләргә походларга чыга. Лангобардларга каршы көрәштә кабат папага ярдәмгә килеп, франклар биек Альп тауларын ике мәртәбә кичеп чыга һәм Италиягә бәреп керә. Карл, лангобардларны тар-мар итеп һәм королен кулга алып, Италиянең күпчелек өлешен үз биләмәләренә куша.

**(5 слайд)** Карл үзенең гаскәре белән берничә тапкыр Испаниягә дә бара. Гарәпләргә каршы сугышлар аңа һәрвакытта да уңыш китергән. Шулай да Пиреней тауларыннан көньяктарак Эбро елгасына кадәр урнашкан бер кечкенә өлкәне яулап алуга ирешә.

**(6 слайд)** Рейн һәм Эльба арасында яшәүче сакс кабиләләренә каршы сугыш иң озакка сузылган һәм иң авыр бәрелеш була. Карл саксларга каршы 8 поход ясый. Хәрби киемнәре булмаган сакслар сугышка таркау төркемнәр булып керә. Көчле атлы гаскәрләре һәм яхшы кораллары булган франклар саксларны җиңәләр. Әмма франклар гаскәре китүгә, сакслар баш күтәрәләр, франклар төзегән крепость һәм монастырьларны җимерәләр, чик буе җирләрен талап бетерәләр.

**(7 слайд) Укучылар, саксларны буйсындыргач, җирле халыкка карата нинди мөнәсәбәт булды икән?** Карл саксларны христиан динен алырга мәҗбүр итә. Ул алар илендә рәхимсез законнар кертә: корольгә аз гына каршылык күрсәткән, чукындырудан яки христиан диненнән баш тарткан өчен үлем җәзасы яный. Чираттагы баш күтәрүгә җавап итеп, **(8 слайд)** Карл 4500 тоткынны җәзаларга боерык бирә. Ул саксларны корольлегенең эчке өлкәләренә күчерә башлый. Әмма бу аяусыз чаралар да ярдәм итми. Сакслар 30 елдан артык азатлык өчен батырларча көрәш алып баралар. Шуннан соң Карл, аксөяк саксларга бүләкләр биреп, күбесен үз ягына аудара, һәм алар басып алучыларга ярдәм итә башлый.

**(9 слайд)** Саксония графлыкларга бүленә. Аксөякләр, епископлар һәм монастырьлар яулап алынган илдә зур җир биләмәләре ала.

Карлның хакимлек итүе тәмамланып килгән чорда күп кенә кабиләләр һәм халыклар аның хакимлеге астына эләгә. Территориясенең зурлыгы ягыннан Франк корольлеге элекке Көнбатыш Рим империясенә якынлаша.

**(10 слайд)** 800 елда Карл Римга килә һәм император дип игълан ителә; храмда папа аңа алтын император таҗын кидерә. Шуннан бирле югары дин әһелләре катнашында тәхеткә утыру йоласы Европада киң тарала башлый.

**(11 слайд**) Белгәнегезчә, Рим җимерелгәннән соң, Бөек Рим империясенең үзәге Көнчыгыштагы Константинопольгә – Көнчыгыш Рим империясе башкаласына күчерелә. Карлның яңа титулы аны Көнчыгыш Рим империясе императоры белән бертигез дәрәҗәгә куя. Хәзер инде Карл үзәге Ахенда булган бөтен көнбатыш христиан дөньясының диярлек идарәчесенә әйләнә. Императорның яулап алу походлары нәкъ менә христиан дөньясының киңәюе белән аклана.

**(12 слайд) Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, шундый зур биләмәләрне Карл ничек контрольлек итеп бетергән икән?** Карл, подданныйлары белән идарә итеп, үзенең ышанычлыларын ияртеп, бөтен дәүләт буйлап йөри. Елга ике тапкыр югары аксөякләр советын җыя һәм алар ризалыгы белән указлар чыгара. Урыннарда элеккечә графлар идарә итә.

**(13 слайд)** Гаять зур ил белән идарә итү өчен, Бөек Карлга укымышлы чиновниклар һәм хөкемдарлар кирәк була. Ул Рим империясен яңадан торгызу өчен мәдәниятне, беренче чиратта антик белемнәрне торгызырга кирәклеген аңлый. Карл заманында мәдәният күтәрелеше башлана, тарихчылар моны *Каролинг яңарышы* дип атый.

**(14 слайд**) Бөек Карл үзенең сараена Италия, Испания, Англия, Ирландиядән белемле кешеләр чакыра, зур монастырьлар каршында мәктәпләр ачарга боера. Мәктәпләр белән идарә итүне укымышлы англо-сакс галиме, монах Алкуинга тапшыра. Алкуин мәгариф эшен оештырып кына калмый, беренче дәреслекләр дә яза.

Император буйсындырылган халыкларның телен, латин телен белгән; буш вакытларында кулын хәрефләр язарга күнектерер өчен, мендәре астына балавызлы табличкалар тоткан, ләкин барыбер язарга өйрәнә алмаган.

**(15 слайд) Франк империясенең гомере озын булганмы соң?** Франк империясе озак яшәми, чөнки ул нык булмый. Франклар басып алган күпсанлы халыклар тик корал көченә генә буйсыналар. Алар үз гореф - гадәтләре белән яши һәм төрле телләрдә сөйләшүләрен дәвам итәләр. Бөек Карл моны яхшы аңлый.

**(16 слайд)** Ыругының гаять зур биләмәләрен югалтуыннан куркып, гомеренең ахырында ул империяне улларына бүлеп бирә. Карлның варислары бертуктаусыз үзара сугышлар алып бара. 843 елда Бөек Карлның өч оныгы Верден шәһәрендә империяне өч өлешкә бүлү турында шартнамә төзиләр. Өлкән оныгы – Лотарь император була. Соңрак элеккеге империянең һәр өлешендә өч зур мөстәкыйль корольлек: Франция, Германия һәм Италия корольлекләре барлыкка килә. Әмма бу дәүләтләр дә озакламый зур биләмәләргә бүленә, ә алар үз чиратларында бик күп вак биләмәләргә таркала. Феодаль таркаулык чоры башлана (IX-XI гасырлар).

**II практик өлеш**

**Беренче бирем.**

Таблицадагы буш урыннарны тутырыгыз

| **Дата** | **Аңлатма** |
|---|---|
| 800 ел | |
| 814 ел | |
| 843 ел | |

**Җаваплар:**

Таблицадагы буш урыннарны тутырыгыз

| **Дата** | **Аңлатма** |
|---|---|
| 800 ел | Карл император дип игълан ителә |

| | |
|---|---|
| 814 ел | Бөек Карл үлгән ел |
| 843 ел | Империянең өч өлешкә бүленүе |

**Икенче бирем.**

**Җитешмәгән сүзләрне языгыз.**

Бөек Карл заманында ______ тере могҗиза – ак ______ пәйдә була. Бу хайван Ганнибал һәм Александр Македонскийның хәрби походлары заманыннан соң европалылар тарафыннан онытылган була һәм мифик _________ кебек кабул ителә. _______ барлык елъязмаларда сурәтләнә, аның һәр көнен дәүләт югарылыгындагы вакыйга итеп сөйлиләр, ә сарай галимнәре үзләре өчен бик күп ______ ясый: мәсәлән, филләрнең ята белүләрен ачыклыйлар.

Сүзләр: фил, бермөгез, ачышлар, Европада, Фил

**Җавап:**

Бөек Карл заманында **Европада** тере могҗиза – ак **фил** пәйдә була. Бу хайван Ганнибал һәм Александр Македонскийның хәрби походлары заманыннан соң европалылар тарафыннан онытылган була һәм мифик **бермөгез** кебек кабул ителә. **Фил** барлык елъязмаларда сурәтләнә, аның һәр көнен дәүләт югарылыгындагы вакыйга итеп сөйлиләр, ә сарай галимнәре үзләре өчен бик күп **ачышлар** ясый: мәсәлән, филләрнең ята белүләрен ачыклыйлар.

**Өченче бирем.**

**Тексттагы тарихи хаталарны табыгыз һәм языгыз.**


Карл саксларны ислам динен алырга мәҗбүр итә. Ул алар илендә рәхимсез законнар кертә: корольгә аз гына каршылык күрсәткән, намаз укудан яки ислам диненнән баш тарткан өчен үлем җәзасы яный. Чираттагы баш күтәрүгә җавап итеп, Карл 4500 тоткынны җәзаларга боерык бирә.

**Дөрес җавап:**

Карл саксларны ~~ислам~~ **христиан** динен алырга мәҗбүр итә. Ул алар илендә рәхимсез законнар кертә: корольгә аз гына каршылык күрсәткән, ~~намаз укудан~~ **чукындырудан** яки ~~ислам~~ **христиан** диненнән баш тарткан өчен үлем җәзасы яный. Чираттагы баш күтәрүгә җавап итеп, Карл 4500 тоткынны җәзаларга боерык бирә.

**Дүртенче бирем.**

**Иҗади бирем**



**Рәсемдә императорны табыгыз. Анда тагын кем сурәтләнгән? Үзегезнең фаразларыгызны аңлатыгыз. Рәссам нинди фикер җиткерергә тели?**